ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

08.11.2019

№ 1654

2020 нче елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә белем алучы балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасынын балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында» 2009 нчы елның 14 нче декабрендәге 854 нче карары һәм Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 нче елга түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә теркәлгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар буенча төзәтү коэффициентын - 0,5 күләмендә.

2. Алабуга муниципаль районын финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.М. Нуриев